**Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы**

**Ятмас-Дусай авыл җирлеге Башлыгы**

**карары**

**2022 елның 2 ноябре** **N25**

**«Кукмара муниципаль районы Ятмас-Дусай авыл җирлеге Ятмас Дусай авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын үткәрүне билгеләү турында»**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Кукмара муниципаль районы Ятмас-Дусай авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә

КАРАР БИРӘМ:

1. 2022 елның 14 ноябренә 14 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Ятмас-Дусай авыл җирлеге Ятмас Дусай авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Ятмас Дусай авылы, Үзәк урамы, 73а йорт адресы буенча урнашкан Ятмас Дусай авылы мәдәният йорты бинасында үткәрергә.

2. 2022 елның 18 ноябренә 14 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Ятмас-Дусай авыл җирлеге Ятмас Дусай авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Ятмас Дусай авылы, Үзәк урамы, 73а йорт адресы буенча урнашкан Ятмас Дусай авылы мәдәният йорты бинасында үткәрергә.

3. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга: «укучылар һәм көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан (курсантлар); I төркем инвалидлардан; 85 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Ятмас-Дусай авыл җирлеге Ятмас Дусай авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән 2023 елда үзара салымны 1000 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүгә сез ризамы:

- Ятмас Дусай авылында вак таш җәеп, юлларны карап тоту һәм ремонтлау (килешү буенча түләү, смета һәм техник күзәтчелек өчен түләү);
- территорияне төзекләндерү һәм карап тоту (килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү, смета, техник күзәтчелек һәм документлар өчен түләү);
- янгынга каршы җиһазлар һәм комплектлау җиһазларын сатып алу, урнаштыру һәм карап тоту (килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү, смета, техник күзәтчелек һәм документлар өчен түләү);
- Ятмас Дусай авылы Үзәк урамы буенча юлны асфальтлау, проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;

- торак пунктка керү һәм чыгу юлында видеокамералар урнаштыру (проект-смета документациясен эшләү);

- Ятмас Дусай авылында су башнясын карап тоту (килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү, смета һәм документация өчен түләү);

-күпер ремонтлау (проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру);

-Ятмас Дусай авылында зиратны карап тоту һәм ремонтлау (хуҗалык инвентаре, ремонт өчен җиһазлар һәм материаллар сатып алу), проект-смета документациясен эшләү;

- Ятмас Дусай авылында юлларны кардан чистарту (проект-смета документларын эшләү, килешү буенча түләү);

-чишмә территориясен ремонтлау һәм төзекләндерү; проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;

-граниттан язулы мемориаль такталар сатып алу һәм урнаштыру;проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру.

«РИЗА» «КАРШЫ»

4. Гражданнар җыенын үткәрү өчен торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген территориаль билге буенча (урамнар буенча) бүләргә.

5. Гражданнар җыенын оештыручы итеп, Ятмас-Дусай авыл Башкарма комитетын билгеләргә.

6. Әлеге карарны кабул ителгән көннән соң 5 көн эчендә мәгълүмат стендларында һәм Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

7. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Ятмас-Дусай авыл җирлеге башлыгы: Ф. Х. Гарифуллина